**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Мусабай-Завод авыл җирлеге составына керүче Таш-Кичу авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**
**КАРАР**

27 октябрь 2023 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2022 елның 20 октябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе тәзелде:

«2024 елда яшәү урыны буенча Мусабай-Завод авыл җирлеге Таш-Кичу авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз илле) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы:
- юл өслегенең юл өлеше астына су уткәрү торбасын өлешчә алмаштыру һәм куаклардан, агачлардан чистарту (махсус техника);;
- урам утларын ремонтлауны хәл итүгә юнәлдерүгә килешәсезме.

ӘЙЕ ЮК».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 173 кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны – 89 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 89 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенында катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Мусабай-Завод авыл җирлеге Таш-Кичу авылында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип танырга.

2. «2024 елда яшәү урыны буенча Мусабай-Завод авыл җирлеге Таш-Кичу авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз илле) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы:
- юл өслегенең юл өлеше астына су уткәрү торбасын өлешчә алмаштыру һәм

куаклардан, агачлардан чистарту (махсус техника);;
- урам утларын ремонтлауны хәл итүгә юнәлдерүгә килешәсезме;» мәсәләсе буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Тукай муниципаль районы Мусабай-Завод авыл җирлеге Таш-Кичу авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка җиткерергә.

4. Тукай муниципаль районы Мусабай-Завод авыл җирлеге Таш-Кичу авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Мусабай-Завод авыл җирлеге Башлыгы З.З. Хөсәинова